**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г. Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2022 елның «14» апреле 971 номер

# КАРАР

**Кадастр номеры 16:24:050802:404 булган җир кишәрлеге территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын әзерләү турында**

Планировка структурасы элементларын бүлеп бирү, гомуми файдаланудагы территорияләр чикләрен, капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү, территорияне планлаштырып үстерү характеристикаларын һәм чиратын билгеләү максатында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 41, 42, 43, 45 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә **карар бирәм**::

1. 16:24:050802:404 кадастр номеры булган җир кишәрлеге территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын әзерләүгә карешергә.
2. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезләмәләре нигезендә проектның эчтәлеген билгеләргә.
3. гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) уздыруны исәпкә алып проектны әзерләү срогын 2022 ел ахырына кадәр билгеләргә.
4. Әлеге Карар басылып чыкканнан соң, физик һәм юридик затларга ундүрт көн эчендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитетына проектны әзерләү тәртибе, сроклары, шулай ук проектны эчтәлеге турында тәкъдимнәр җибәрергә тәкъдим итәргә.
5. Әлеге проектны әзерләү эшләрен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә йөкләргә.
6. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация четәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

.

**Җитәкче** **А.А. Новиков**